Татар мәктәбендә укучы балаларга татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр
5 нче сыйныф 2016-2017 уку елы

**Максималь балл – 44** *Үткәрү вакыты - 60 минут*

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1.Калын сузык авазлардан гына торган сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***
- а) өстәл, тәлинкә, чәйнек, гөбәдия;
- ә) егет, тукран, йокы, алъяпкыч;
- б) туфрак, елга, болыт, кулъяулык;
- в) юрган, келәм, тәрәзә, ишек.

2. Яңгырау тартык авазлар гына кергән сүзләрдән торган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
- а) Балыкчы бик күп балык тотты.
- ә) Зилә бүген урманга гөмбәгә барды.
- б) Песиебез йомгак белән уйный.
- в) Төлкенең койрыгы зур.

3.Ачык иҗекләрдән генә торган сүзләр кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
- а) Егетләр чана шуа. ә) Тиен чикләвек җыя. б) Бала су коена. в)Үрдәкләр һавада оча.

4.Ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***
- а) кошчыгым, әнкәй, бүген;
- ә) улым, мәктәбебез, авыллары;
- б) алмагач, шифаханә, көньяк;
- в) бүлмә, сатучы, яхшылык.

5.Синонимнардан гына торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***
- а) матур, гүзәл, сылу, чибәр; ә) өши, туңа, эссе, җылы;
- б)көн, төн, иртә, кич; в) ак, кара, сары, яшел.

6.Җөмләдә кулланылган күплек сандагы исемнәрнең санын билгеләгез. ***(2 балл)***

*Уң яктагы чокыр төбендә бөрлегәннәр, тәлгәшләрен күтәрә алмыйча, якты кояш нурында янып, матурланып, кызарып утыра.*
- а) 1; ә) 2; б) 3; в) 4.

7. Тартым белән төрләнгән исемнәр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***
- а) кош, кошчык, кошлар;
- ә) алма, алманың, алмага;
- б) әнием, китабы, хатларың;
- в) дәфтәрләр, чишмәләр, күлләр.

8. Тәртип саны кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
- а) Беренче сентябрьдә җылы булса, бөтен көз җылы булыр. (Сынамыш);
- ә) Ашыккан бер эшне ике эшләр. (Мәкаль).
- б) Җиде кат үлчә, бер кат кис. (Мәкаль);
- в)Ике сигезең уналты икәнен кем дә белә. (Мәкаль)

9. Аергыч кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
- а) Эш кешене ныгытыр. (Мәкаль)
- ә) Хөрмәт сөйсәң, хезмәт сөй. (Мәкаль)
- б) Туры сүз - телнең бизәге. (Мәкаль)
- в) Корал эшләр, ир мактаныр. (Мәкаль)

10. Эндәш сүз кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
- а)Миләүшә Илдаровна “Оста куллар” түгәрәгең җитәкли.
- ә) 5 нче сыйныф җитәкчесе – Ләйсән Камиловна.
- б) Укучылар, ата-аналар өмәгә җыелды.
- в) Илшат Мансурович, керергә ярыймы?

11. Җөмләнең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Фәнис Яруллин шигъри образлар ярдәмендә гүзәл рәсемнәр иҗат итә.* (Ф.Шәфигуллин)
- а) боеру; ә) хикәя; б) сорау; в) тойгылы.

12. Җыйнак җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
- а) Укучылар укыйлар. ә) Китап укыдым. б) Авылда яшибез. в) Алтын көз.

**II. Теоретик бирем.**

Омонимнарга билгеләмә бирегез, 5 омоним парның мәгънәләрен җөмләләр ярдәмендә аңлатып языгыз. ***(10 балл)***

**III. Иҗади бирем.**

Сүзләргә сузык авазлар өстәп, мәкальне укыгыз. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(10 балл)***

ХЗМТ ТБ – ХРМТ.